**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә.**

2024 елның 15 феврале

Халык алдында тыңлаулар Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгы - Совет рәисе инициативасы белән үткәрелде, 2023елның 25 декабрендәге 147-РС номерлы карар белән билгеләнде.

Хәерби авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында 2023елның 25 декабрендәге 147-РС номерлы карары Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2023елның 29 декабрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә;
2. 2023елның 27 декабрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы» («Камская новь») газетасында;
3. 2023елның 29 декабрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Хәерби авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларда катнашучылар - җирлек территориясендә даими яшәүче гражданнар, әлеге территория чикләрендә урнашкан һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, шулай ук әлеге капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар уздыру сроклары, проектның мәгълүмати материаллары, проект материаллары экспозициясен уздыру сроклары һәм урыны, катнашучылар җыелышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында, проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү тәртибе турында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 10 гыйнварындагы 7/исх номерлы белдерүе белән хәбәр ителделәр.

Ачык тыңлаулар башлану турында 2024 елның 10 гыйнварындагы 7/исх хәбәр басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2024 елның 11 гыйнварында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегенең рәсми сайтында;

2. 2024 елның 19 гыйнварында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы»(«Камская новь») газетасында (мәгълүмат хәбәрләрен бастырып чыгару юлы белән);

3. 2024 елның 25 гыйнварында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларны оештыручы: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты.

Рәислек итүче: Карсалов Алексей Петрович - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы.

Ачык тыңлаулар секретаре: - Зинәтуллин Р.К. - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты материаллары экспозициясе 2024 елның 29 гыйнварыннан 2024елның 2 февраленә кадәр үткәрелде.

Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә 2023 елның 29 ноябрендә Хәерби авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе нигезендә төзелде.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2024 елның 29 гыйнварыннан 2024елның 2 февраленә кадәр проект экспозициясен үткәрү барышында, шулай ук гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында кабул ителде.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә Хәерби авыл җирлегенең 2024елның14 февралендәге Җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәсе нигезендә төзелгән.

Ачык тыңлауларда 15 кеше катнашты.

Ачык тыңлаулары нәтиҗәләре:

1.Халык тыңлауларын узган дип танырга;

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын, 2024 елның 14 февралендәге ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм бәяләмәне, проектны йомгаклап раслау өчен, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә;

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә гамәлдәге законнар нигезендә әлеге нәтиҗәдән өземтәләр бирергә.

Ачык тыңлаулар рәисе __________________________ Карсалов А.П.

Ачык тыңлаулар секретаре ________________________ Зинәтуллин Р.К.